КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1049

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 741 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Торак урынны наемга бирү шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә түбәндәге эчтәлекле $13^1$ нче пунктны өстәргә:

«$13^1$. Муниципаль берәмлекләрнең агымдагы финанс елында субсидияләр акчасына ихтыяҗы булмаган очракта, янга кала торган акча 1 ноябрьгә кадәр бу Кагыйдәләр нигезендә субсидия алырга хокукы булган башка муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган Торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча торак алучы гражданнарның исемлекләрен төзү һәм раслау тәртибенең 20 нче пунктында каралган тәртиптә яңадан бүленә.»;

әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

7 нче пунктта «тиешле» сүзен «агымдагы» сүзенә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $13^1$ һәм $13^2$ пунктларны өстәргә:

«$13^1$. Муниципаль берәмлекләрнең агымдагы финанс елында субсидияләр акчасына ихтыяҗы булмаган очракта, җирле үзидарә органы 1 октябрьгә кадәр бу турыда Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша Министрлыкка хәбәр итә.

$13^2$. Министрлык, бу Кагыйдәләрнең $13^1$ нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматны алганнан соң, агымдагы финанс елының 1 ноябренә кадәр муниципаль берәмлекләрдән субсидияне өстәмә бирүгә заявкалар кабул итүне башкара.

Башка муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында янга калган субсидияләр акчасын яңадан бүлү бу Кагыйдәләрнең 12 нче пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен төзү һәм раслау тәртибенә түбәндәге эчтәлекле 20 нче пунктны өстәргә:

«20. Агымдагы финанс елында Министрлык тарафыннан чираттагы финанс елына расланган һәм тәгаенләштерелгән җыелма исемлеккә кертелгән гражданнан бу Тәртипнең 11 нче пунктында күрсәтелгән гариза кергән очракта, җирле үзидарә органы бу турыда Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша Министрлыкка хәбәр итә.

Агымдагы елда муниципаль берәмлекнең субсидиягә ихтыяҗы булмаган очракта, Министрлык җирле үзидарә органы мөрәҗәгате буенча, бу пунктта каралган нигезләргә һәм (яки) бу Тәртипнең 19 нчы пунктына таянып, расланган исемлеккә үзгәрешләр кертә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин